| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**2016 елның 10 марты** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 03-03-544** |

Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча торак биналарны кабул итү-тапшыру тәртибен раслау турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча муниципаль адреслы программаны гамәлгә ашыру максатларында, РФ Торак кодексына, 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы “Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм фонды турында”гы Федераль законга таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районында авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча торак биналарны кабул итү - тапшыру тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. “ЗМР финанс-бюджет палатасы” муниципаль учреждениесенә яшәү өчен яраксыз (авария хәлендәге) йортларда урнашкан һәм гражданнар тарафыннан муниципалитетка кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырылган торак биналар өчен торак-эксплуатация идарәсе буенча түләү чыгымнарын финанслауны күздә тотарга.
3. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгы А. Н.Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталына урнаштыру юлы белән тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче А. Х.Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль
районы Башкарма комитеты
2016 елның 10 мартындагы
03-03-544 номерлы карарына
кушымта

**Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча торак биналарны кабул итү - тапшыру тәртибе**

1. Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча торак биналарны кабул итү - тапшыруның әлеге тәртибе Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 26 сентябрендәге 2178 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында яшәү өчен яраксыз (аварияле) йортларда урнашкан һәм авария хәлендәге торак фондыннан гражданнарны күчерү буенча муниципаль адреслы программа нигезендә күчерелергә тиешле торак биналарның милекчеләрен, яллаучыларны (алга таба гражданнар) азат итүне регламентлый.

2. Зеленодольск муниципаль районында гражданнарны авария хәлендәге торак фондыннан күчерү буенча торак биналарны кабул итү - тапшыру тәртибе РФ Гражданнар, Торак кодексы, 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итүче фонд турында» Федераль закон нигезендә эшләнгән.

3. Торак бина, торак урынны муниципаль милеккә сатып алган яисә гамәлдәге торак законнары нигезендә, башка торак бина биргән очракта, гражданнар тарафыннан азат ителергә тиеш.

4. Торак бинаны азат итү түбәндәге документлар нигезендә гамәлгә ашырыла:

4.1.милекчеләр өчен: торак бинаны муниципаль милеккә сатып алу шартнамәсе, тигез кыйммәтле торак бина бирелгән очракта - торак бирү турында документ (шартнамә, суд карары);

4.2. социаль наем шартларында яшәүче яллаучылар өчен: бертигез дәрәҗәдә торак бина бирү турындагы документ (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары, суд карары).

5. Торак бинаны кабул итү-тапшыру акты буенча торак бинаны тапшырганчы гражданнар бурычлы: булган бурычны да кертеп, торак-эксплуатация идарәсе өчен түләүне башкарырга, торак бинаны җимерүгә юл куймаска, аерым алганда, тәрәзәләргә, ишекләргә, бүлмә стеналарына, инженерлык җиһазларына, җылылык системасына демонтаж ясамаска, башка затларны кертмәскә.

6. Торак-эксплуатация идарәсе өчен түләү, бурычны да кертеп,

гражданнар тарафыннан фатирны тапшыру актына кул куйганчы түләнергә тиеш.

7. Торак бина Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсеннән төзелгән комиссия кабул итү-тапшыру акты буенча гражданнар тарафыннан тапшырылырга тиеш.

8. Торак биналарны кабул итү - тапшыру комиссиясе составына түбәндәге оешма вәкилләре керә: «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ, «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ, «Зеленодольск муниципаль районының торак-коммуналь хуҗалыгы департаменты» МБУ, «Зеленодольскгаз» Эксплуатация-җитештерү идарәсе, «Татэнергосбыт» АҖО, «Водоканалсервис» АҖО.

9. Торак бинаны кабул итү-тапшыру датасы турында гражданнарга «Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты» МКУ алдан ук хәбәр ителә.

10. Торак бинаны бушату (азат итү) вакыты түбәндәге вакыттан 14 көннән арта артмаска тиеш:

9.1 торак бина бирмичә торак урынны тартып алу, дәүләт теркәве органнарында торак бина сатып алу шартнамәсен теркәү;

9.2 гамәлдәге торак законнары нигезендә башка торак бина бирелгән очракта, бирелгән торак бинага керергә рөхсәт бирү.

11. Торак бинаны кабул итү-тапшыру вакытына гражданнар бинаны җиһазлардан һәм шәхси әйберләрдән азат итәргә тиеш.

12. Торак бинаны кабул иткәндә, әлеге Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән комиссия торак бинаның торышын, инженерлык җиһазларының булуын тикшерергә һәм җитешсезлекләрне, акттагы кисәтүләрне кире кагарга, бинадан ачкычлар алырга һәм аны ябарга бурычлы.

13. Кабул итү-тапшыру акты 3 нөсхәдә төзелә, шуларның берсе торак бина милекчесенә (яллаучыга) тапшырыла.

14. Торак бинаны кабул итү-тапшыру акты, торак бинаның ачкычлары «Зеленодольск муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы» МУ комиссияләр тарафыннан тапшырыла.

15. “Зеленодольск муниципаль районының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы” МУ муниципалитетка тапшырылган торак биналарның, яшәү өчен яраксыз (авария хәлендәге) йорт тулысынча күчерелгәнче, сакланышын тикшереп тора.

16. “Зеленодольск муниципаль районының торак сәясәте департаменты” МКУ бөтен йорт тикшерелгәннән соң, торак-коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләргә йортны тиешле төрдәге коммуникацияләрдән сүндерү кирәклеге турында мәгълүматны җиткерә.